КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

2023 ел, 17 март

г.Казань

№ 263

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Озак вакытлы чорга Татарстан Республикасының бюджет фаразын эшләү һәм раслау тәртибе турында» 2015 ел, 15 сентябрь, 676 нчы карары белән расланган Озак вакытлы чорга Татарстан Республикасының бюджет фаразын эшләү һәм раслау тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Озак вакытлы чорга Татарстан Республикасының бюджет фаразын эшләү һәм раслау тәртибе турында» 2015 ел, 15 сентябрь, 676 нчы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 26 гыйнвар, 30 нчы; 2021 ел, 6 февраль, 61 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Озак вакытлы чорга Татарстан Республикасының бюджет фаразын эшләү һәм раслау тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Бюджет фаразын булдыру (Бюджет фаразына үзгәрешләр кертү) максатларында Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы рәсми басылып чыккан көннән биш эш көненнән дә артмаган срок эчендә Озак вакытлы фараз (Озак вакытлы фаразга үзгәреш кертү) параметрларын һәм аларга аңлатма язуын Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына җибәрә.»;

5 пункт үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры

А.В.Песошин